БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
16 декабрь 2020 ел

**КАРАР**
№ 29

**2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1 пункт

1. 2021 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең гомуми күләмен 928424,41 мең сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 928424,41 мең сум итеп;

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын 0 сум итеп.

2. 2022-2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2022 елга Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең гомуми күләмен 927436,21 мең сум һәм 2023 елга 933410,81 мең сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен:

- 2022 елга 927136,21 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 9837,0 мең сум итеп;

- 2023 елга 933410,81 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 20857,0 мең сум итеп.

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын 2022 елга 0 сум һәм 2023 елга 0 сум итеп.

3. Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

- 2021 елга әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә;

- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә.

2 пункт

1. 2021 елның 1 гыйнварына Балтач муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 сум итеп, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум итеп билгеләргә.

2. 2022 елның 1 гыйнварына Балтач муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 сум итеп, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум итеп билгеләргә.

3. 2023 елның 1 гыйнварына Балтач муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 сум итеп, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бурычының иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

- 2021 елда - 0 сум итеп;
- 2022 елда - 0 сум итеп;
- 2023 елда - 0 сум итеп.

3 пункт

Балтач муниципаль районы бюджетында 2021 елга фаразлана торган керем күләмен әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә, 2022 һәм 2023 еллар план чорына, әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

4 пункт

1. Балтач муниципаль районы бюджеты keremнәренең баш администраторлары - Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары - исемлеген әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары - Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә расларга.

5 пункт

1. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

- 2021 елга әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә;
- 2022 һәм 2023 еллар план чорына әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә.

2. Балтач муниципаль районы чыгымнарының ведомство структурасын түбәндәгечә расларга:

- 2021 елга әлеге карарның 9 нчы кушымтасы нигезендә;
- 2022 һәм 2023 еллар план чорына әлеге карарның 10 нчы кушымтасы нигезендә.

6 пункт

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

- әлеге карарның 11 нче кушымтасы нигезендә бүленеш белән, 2021 елга 25760,50 мең сум итеп;

- әлеге карарның 12 нче кушымтасы нигезендә бүленеш белән, 2022 елга - 22459,20 мең сум, 2023 елга - 21331,00 мең сум итеп.

7 пункт

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

- 2021 елга әлеге карарның 13 нче кушымтасы нигезендә бүленеш белән 1999,0 мең сум итеп;

- 2022 елга - 2020,20 мең сум, 2023 елга - 2102,00 мең сум итеп, әлеге карарның 14 нче кушымтасы нигезендә бүленеш белән.

8 пункт

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү өчен һәм торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд акчалары хисабына финанс ярдәме алу өчен Балтач муниципаль районы бюджетында түбәндәгеләрне исәпкә алырга:

1) күпфатирлы торак йортларга капиталь ремонт ясау чараларын тәэмин итү өчен район бюджетына Балтач шәһәр җирлеге бюджетыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертларны төзелгән килешү нигезендә ел саен 1128 мең сум итеп.

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 декаберендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән Балтач муниципаль районы бюджетында түбәндәгеләрне исәпкә алырга:

2) әлеге карарның 15 нче, 16 нчы кушымталары нигезендә тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларыннан район бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертларнытөзелгән килешүләр нигезендә ел саен 209,8 мең сум итеп.

Тиешле җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына әлеге пунктта күрсәтелгән бюджетара трансфертларны җирлекләр бюджетларында алдан исәпкә алырга.

9 пункт

1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган түбәндәге бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:

- әлеге карарның 17 нче кушымтасы нигезендә 2021 елда 617950,61 мең сум итеп;

- әлеге карарның 18 нче кушымтасы нигезендә 2022 елда 608628,41 мең сум һәм 2023 елда 593364,51 мең сум итеп.

10 пункт

1. Бюджет ассигнованиеләренең максатчан статьялары (дәүләт һәм Балтач муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнарының классификацияләү бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

- 2021-2023 елларга әлеге карарның 19 нчы, 20 нче кушымталары нигезендә.

11 пункт

Балтач муниципаль районы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2021 елга 16000 мең сум, 2022 елга 16800 мең сум, 2023 елга 16900 мең сум итеп расларга һәм аларны тиешенчә 2021, 2022 һәм 2023 елларга Балтач муниципаль районының гомуми файдалану юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.

12 пункт

1. 2021 елда һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорында Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына бюджет кредитлары бирелми дип билгеләргә.

13 пункт

1. Балтач муниципаль районы муниципаль хакимияте органнары 2021 елда һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалар хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук аларны карап тотуга киткән чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2021 елда муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалар хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

14 пункт

1. Балтач муниципаль районы бюджетын үтәгәндә фактта алынган, әлеге Карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән арткан керемнәр, билгеләнгән тәртиптә әлеге Карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль бурыч алуларны биләүгә муниципаль бурычны түләүгә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясының 3 пунктында аларны үтәүгә каралган күләмдә бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә.

Балтач муниципаль районы бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрдән тыш фактта алынган субсидияләр һәм субвенцияләр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертеп, субсидияләр һәм субвенцияләр бирү максатларында чыгымнарны арттыруга юнәлдерелә.

15 пункт

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Балтач муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

16 пункт

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

17 пункт

Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

18 пункт

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджетны формалаштыру, икътисад һәм социаль-икътисадый үсешне фаразлау буенча даими комиссиягә (рәисе Р.Х.Һадиев) йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин